| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАДЕЖДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2019 **Надеждино авылы** №9

**Надеждино авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокукларын гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елнын 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Надеждино авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны, җирле референдум мәсьәләләрен формалаштырып, түбәндәгечә тәкъдим итәргә:

"Сез 2020 елда 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә хокуклы Надеждино авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү кертүгә килешәсезме?

*а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- сүүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм монын өчен материаллар сатып алу;

*б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмати стендларда һәм Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http:// nadegd__-kaybici.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советына җибәрергә.

4. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Надеждино авыл җирлеге**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Татарстан Республикасы** **Е.В.Савельева**